КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 сентябрь г.Казань № 828

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә теркәлгән 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче, 2016 ел, 15 февраль, 73 нче, 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү

тәртибенә теркәлгән 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 19 нчы пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «19. | Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә билгеләнгән тәртиптә басылып чыккан норматив хокук актлары өлеше, процент | Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы | квартал саен | V = A / B × 100, монда:<br>A – хисап чоры өчен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә басылып чыккан муниципаль норматив хокук актлары саны, берәмлек;<br>B – хисап чорында басылып чыккан муниципаль норматив хокук актларының гомуми саны, берәмлек». |

2. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин